ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 14 » май 2026 ел № 389

**Капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерү турында карар бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында**

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, "Рреспублика башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын турында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты Татарстан КАРАР БИРӘ:

1. Капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерү турында карар бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының түбәндәге карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

- "Арча муниципаль районы территориясендә капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерү турында карар бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында" 2017 елның 06 июлендәге 890 номерлы;

- "Капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше йөзен

килештерү турында карар бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 2021 елның 10 августындагы 569 номерлы.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.arsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары И.Ә. Галимуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Л.И.Абдуллин

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы Башкарма
комитеты карарына
“14” 05 2026 ел, №389
кушымта

# Капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерү турында карар бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге Административ регламенты (алга таба – Регламент) капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерү турында карар бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели (алга таба – муниципаль хезмәт).

2. Муниципаль хезмәтне алучылар: физик һәм юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр (алга таба – мөрәҗәгать итүче).

Мөрәҗәгать итүчеләрнең мәнфәгатьләрен мөрәҗәгать итүче тарафыннан билгеләнгән тәртиптә вәкаләт бирелгән затлар һәм физик затларның законлы вәкилләре (алга таба – мөрәҗәгать итүче вәкиле) тәкъдим итәргә мөмкин.

3. Муниципаль хезмәт мөрәҗәгать итүчегә мөрәҗәгать итүченең категорияләре (билгеләре) нигезендә күрсәтелергә тиеш, алар “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы” (алга таба – Бердәм портал) федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла.

## II. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

### Муниципаль хезмәт исеме

4. Капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерү турында карар бирү.

### Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган исеме

5. Муниципаль хезмәтне Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге (алга таба – Башкарма комитет) күрсәтә.

### Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе

6. Мөрәҗәгать итүче “Капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерүне” сорап мөрәҗәгать иткәндә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре булып тора:

1) капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерү турында карар (1 нче кушымта);

2) муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар (2 нче кушымта).

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак реестр язмасын формалаштыру каралмаган.

Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүченең сайлавы буенча муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән җибәрелә.

7. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә “Электрон имза турында” 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә Башкарма комитет вазыйфаи затының (яки Башкарма комитет) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә бердәм порталдагы, республика порталындагы шәхси кабинетына җибәрелә.

8. Мөрәҗәгать итүченең сайлавы буенча муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе КФҮдә Башкарма комитет тарафыннан җибәрелгән, кәгазьдә бастырылган, КФҮ мөһере һәм КФҮ хезмәткәре имзасы белән таныкланган электрон документ нөсхәсе рәвешендә алырга мөмкин.

9. Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ яисә электрон документның кәгазьдәге нөсхәсе рәвешендә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең гамәлдә булу срогы дәвамында алырга хокуклы.

## Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы

10. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең максималь срогы, мөрәҗәгать итүченең категориясенә (билгеләренә) бәйсез рәвештә, бердәм портал, республика порталы аша Башкарма комитетка, КФҮгә мөрәҗәгать иткәндә 10 эш көненнән дә артмый.

Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы гариза теркәлгән көннән соң икенче көнгә исәпләнә башлый.

11. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогын туктатып тору каралмаган.

12. Электрон документ рәвешендә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документны җибәрү муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштергән һәм теркәгән көнне гамәлгә ашырыла.

## Гаризаны һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге һәм муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

13. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гаризаларны һәм документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карарны түбәндәге нигезләр булганда Башкарма комитет кабул итә:

1) мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларда текстны Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган чистартулар һәм төзәтүләр була;

2) документларда муниципаль хезмәт күрсәтү өчен документлардагы мәгълүматтан һәм белешмәләрдән тулы күләмдә файдаланырга мөмкинлек бирми торган зарарланулар була;

3) тапшырылган документлар яисә белешмәләр муниципаль хезмәтне сорап мөрәҗәгать итү вакытына үз көчен югалткан (шәхесне таныклаучы документ белешмәләре; мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен таныклаучы документ, күрсәтелгән зат тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать ителгән очракта);

4) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гарызнамәне һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны билгеләнгән таләпләрне бозып электрон рәвештә бирү;

5) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы булмаган комплектын тапшыру;

6) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза вәкаләтләренә муниципаль хезмәт күрсәтү кермәгән дәүләт хакимияте органына, җирле үзидарә органына яисә оешмага тапшырылган;

7) “Электрон имза турында” 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясында билгеләнгән чынбарлыкны, көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаны тану шартларын үтәмәү;

8) мөрәҗәгать итүче категориясенең хезмәт күрсәтү алу хокукына ия затлар даирәсенә туры килмәве.

14. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк.

15. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турындагы карарны Башкарма комитет түбәндәге нигезләр буенча кабул итә:

1) архитектура-шәһәр төзелеше йөзе килештерелергә тиеш булмаган объектка (объектлар төркеменә) карата архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерүне сорап мөрәҗәгать итү;

2) төзелә торган объектка карата архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерүне сорап мөрәҗәгать итү, ә территориянең хәзерге торышын анализлаганда җир кишәрлегендә төп тышкы характеристикалары буенча архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерү турында гариза рәсмиләштерелгән объектка охшаш объектның (төгәлләнмәгән төзелеш объектының, төзелеш-монтаж эшләре башланган объектның) булуын ачыклау;

3) реконструкцияләнә торган объектка карата архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерүне сорап мөрәҗәгать итү, ә территориянең хәзерге торышын анализлаганда объектның җир кишәрлегендә булмавын ачыклау (төгәлләнмәгән төзелеш объектын, төзелеш-монтаж эшләре башланган объектны да кертеп);

4) реконструкцияләнә торган объектка карата архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерүне сорап мөрәҗәгать итү, ә объектның хәзерге торышын анализлаганда төп тышкы характеристикалар буенча объектның хәзерге торышы архитектура-шәһәр төзелеше йөзе материалларында күрсәтелгән реконструкция буенча тәкъдимнәргә охшаш булуын ачыклау;

5) тапшырылган материалларда каршылыклар булу;

6) төрле функциональ билгеләнештәге объектлар төркеменә карата бер гариза белән мөрәҗәгать итү, моңа торак булмаган билгеләнештәге объектлар һәм

янәшәдәге һәм хезмәт күрсәтүче инфраструктура объектлары; социаль билгеләнештәге объектлар һәм янәшәдәге һәм хезмәт күрсәтүче инфраструктура объектлары керә торган объектлар төркеменең архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерү турында гариза белән мөрәҗәгать итү очраклары керми;

7) шундый ук күпфатирлы торак йортның архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерү турында карар моңа кадәр кабул ителмәгән дип билгеләнгән булу;

8) объектның элек килештерелгән архитектура-шәһәр төзелеше йөзенең параметрларын үзгәртүне сорап мөрәҗәгать иткәндә, объектның элек килештерелгән архитектура-шәһәр төзелеше йөзенең төп тышкы характеристикалары буенча архитектура-шәһәр төзелеше йөзе материалларында күрсәтелгән төзелеш (реконструкция) буенча тәкъдимнәргә охшаш булуы билгеләнгән булу;

9) объектның элек килештерелгән архитектура-шәһәр төзелеше йөзенең параметрларын үзгәртүне сорап мөрәҗәгать иткәндә, объектның архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерү турындагы карар элек кабул ителмәгән дип билгеләнгән булу;

10) күпфатирлы торак йортның-аналогының архитектура-шәһәр төзелеше йөзе материаллары һәм элек архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерү турында қарар кабул ителгән йортның архитектура-шәһәр төзелеше йөзе материаллары арасында туры килмәүләр булу;

11) капиталь төзелеш объекты параметрларының капиталь төзелеш объекты урнашкан территориядә шәһәр төзелеше эшчәнлеген регламентлаштыра торган норматив документациягә, җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планына туры килмәве;

12) капиталь төзелеш объектының күләм-планлаштыру һәм архитектура-сәнгать (шул исәптән: силуэт, композицион, декоратив-пластик, стилистик, колористик) характеристикаларын барлыкка килгән төзелешкә шәһәр төзелеше интеграциясенең җитәрлек булмавы;

13) территориянең пространстволы оештыруның һәм функциональ билгеләнешенең, шул исәптән тарихи, табигый-ландшафт, планлаштыру, композиция, археология һәм мохит нигезләренең барлыкка килгән үзенчәлекләрен исәпкә алмыйча күләм-планлаштыру һәм архитектура-сәнгати чишелешләрне үтәү;

14) тәкъдим ителә торган күләм-планлаштыру һәм архитектура-сәнгати чишелешләрне гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә мохит характеристикаларының начараюы һәм яшәеш өчен уңайлы мохитнең тотрыклы формалашуын җитәрлек дәрәҗәдә тәэмин итмәү;

15) мәдәни мирас объектының саклау зонасы чикләрендә объектны урнаштыру яисә реконструкцияләү мөмкин түгеллеге турында вәкаләтле органның бәяләмәсе керү;

16) мөрәҗәгать итүче инициативасы буенча муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризаны кире алу.

16. Гаризаны һәм хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр, мөрәҗәгать итүченең категориясен (билгеләрен) исәпкә алып, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр регламентның 4 нче кушымтасында китерелгән.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

17. Муниципаль хезмәт күрсәткән өчен түләү алу Россия Федерациясе законнарында каралмаган.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты

18. Муниципаль хезмәт алуга гариза биргәндә көтү вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

19. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта торуның максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

Мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гарызнамәсен теркәү срогы

20. КФҮгә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә гариза бирелгән көнне гариза бирүчегә КФҮ АМСтан гаризаның җибәрелгәнлеген раслаучы теркәлү номеры һәм гариза бирелгән дата белән расписка бирелә.

21. Гаризаны бердәм портал, республика порталы аша җибәргәндә, гариза биргән көнне мөрәҗәгать итүче республика порталындагы шәхси кабинетында һәм электрон почта аша гаризаның җибәрелгәнлеген раслый торган, теркәлү номерын һәм гариза биргән датаны күрсәтеп, хәбәрнамә ала.

22. Гариза бирелгән көнне башкарма комитетка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә башкарма комитетның вәкаләтле вазыйфаи заты гаризаны кабул итү датасын һәм аңа кушып бирелгән документларны күрсәтеп, ике нөсхәдә мөрәҗәгать итүчегә бер нөсхә кире кайтарыла.

Муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган биналарга таләпләр

23. Муниципаль хезмәт янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә күрсәтелә.

Мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итү урыннары документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырыла.

24. Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү максатларында җәэмин ителә:

1) инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү мөмкинлеге (биналарга/биналардан керү/чыгу һәм алар чикләрендә хәрәкәт итү уңайлылыгы);

2) муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның мөмкинлекләре чикләнгән урыннарда урнаштырылган визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат;

3) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясе тотрыклы бозылулары булган инвалидларны озата бару һәм аларга ярдәм күрсәтү;

4) социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектлары урнашкан территориядә мөстәкыйль хәрәкәт итү, мондый объектларга керү һәм алардан чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү, шул исәптән кресло-коляска кулланып, мөмкинлеге;

5) инвалидларның тормыш эшчәнлеге чикләүләрен исәпкә алып, муниципаль хезмәт күрсәтүләргә тоткарлыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат саклагычларын тиешенчә урнаштыру;

6) инвалидлар өчен кирәкле тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язмаларны, билгеләрне һәм башка текст һәм график мәгълүматны Брайльнең рельефлы-нокталы шрифты белән башкарылган билгеләр белән кабатлау;

7) сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;

8) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының “Йөртүче этне махсус өйрәтүне раслый торган документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турындагы” 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән билгеләнгән формада һәм тәртиптә бирелгән махсус йөрәтелгәнлеген раслаучы документ булганда йөртүче этне кертү.

25. Регламентның 24 пунктының 1-4 пунктчаларында күрсәтелгән хезмәтләр күрсәтелә торган объектлардан һәм хезмәтләр күрсәткәндә кулланыла торган чаралардан инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү өлешендәге таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яки модернизацияләнгән, реконструкцияләнгән объектларга һәм чараларга карата кулланыла.

26. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга таләпләр турындагы мәгълүмат Башкарма комитетның, КФҮнең рәсми сайтында, шулай ук Бердәм һәм Республика порталларында урнаштырыла.

## Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булуын һәм сыйфатын билгеләүче күрсәткечләр

27. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәкрем файдалана алырлык булуын билгеләүче күрсәткечләр:

документлар кабул итү, бирү алып барыла торган бинаның җәмәгать транспортыннан файдалана алырлык зонада урнашуы;

кирәкле сандагы белгечләр, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган урыннар булу;

мәгълүмат стендларында, муниципаль районның рәсми сайтында, Бердәм порталда, Республика порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында тулы мәгълүмат булу;

инвалидларга башка затлар белән берләттән хезмәт алуга комачаулый торган киртәләрне җиңүдә ярдәм күрсәтү.

28. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып тора:

1) документларны кабул итү һәм карау вакытларын үтәү;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу вакытын үтәү;

3) Башкарма комитет хезмәткәрләре тарафыннан регламент бозылуга нигезләнгән шикаятьләрнең булмавы;

4) мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән үзара эшчәнлек саны (консультацияләрне исәпкә алмыйча):

4.1) гаризаны барлык кирәкле документлар белән тапшырганда мөрәҗәгать итүченең КФҮ хезмәткәрләре белән үзара эшчәнлеге бер мәртәбә гамәлгә ашырыла;

4.2) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен КФҮдә электрон документның кәгазьдәге нөсхәсе рәвешендә алырга кирәк булган очракта бер тапкыр гамәлгә ашырыла.

Хезмәт күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән бер хезмәттәшлек итү вакыты 15 минуттан артмый.

Мөрәҗәгать итүче хәрәкәтчән радиотелефон элемтәсе җайланмалары ярдәмендә, Бердәм порталдан, Республика порталыннан, терминал җайланмалардан файдаланып муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфатын бәяләргә хокуклы.

29.Хезмәт күрсәтүнең мөрәҗәгать итүчеләрнең ихтыяҗларына туры килү-килмәвен тикшерү Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты карары белән билгеләнгән кире элемтәне анализлау нигезендә даими үткәрелә.

Хезмәт күрсәтү процессларын оптимальләштерү мөрәҗәгать итүчеләрнең хезмәт күрсәтү процессыннан канәгатьлек дәрәҗәсе тотрыклы кимегән очракта (оч айдан артык рәттән) башкарыла.

Хезмәт күрсәтү процессы белән канәгатьлек дәрәҗәсе кимемәгән очракта, оптимальләштерү кимендә биш елга бер тапкыр үткәрелә.

30. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы һәм статусы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Бердәм порталдагы шәхси кабинетта яисә Республика порталында, күп функцияле үзәктә алынырга мөмкин.

31. Муниципаль хезмәт күрсәтү мөрәҗәгать итүче сайлаган теләсә кайсы КФҮдә аның яшәү урынына яисә фактта яшәү (булу) урынына бәйсез рәвештә экстерриториаль принцип буенча башкарыла.

32. Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәтне комплекслы сорау составында алырга хокуклы.

33. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфат һәм һәркем файдалана алырлык күрсәткечләре турында мәгълүмат Башкарма комитетның рәсми сайтында, КФҮдә, шулай ук Бердәм һәм Республика порталларында урнаштырыла.

Муниципаль хезмәт күрсәтүгә башка таләпләр

34. Муниципаль хезмәтне электрон рәвештә күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм вакытлары турында Бердәм порталда, Республика порталында урнаштырылган мәгълүмат алырга;

б) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон образлары элек 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1 өлешенең 7.2 пункты нигезендә танылканган документларны һәм мәгълүматны Бердәм порталдан, Республика порталыннан файдаланып тапшырырга;

в) муниципаль хезмәт күрсәтү турында электрон рәвештә бирелгән гаризаларның үтәлеше барышы һәм статусы турында белешмәләр алырга;

г) муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфатын Бердәм портал, Республика порталы ярдәмендә бәяләргә;

д) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ рәвешендә алырга;

е) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, аларның вазыйфаи затлары, муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелгәндә кылынган карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процессын тәэмин итә торган Бердәм портал, Республика порталы, федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы аша Башкарма комитетның, шулай ук аның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең карарына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

35. Гаризаны формалаштыру гаризаның электрон рәвешен Бердәм портал, Республика порталында башка формада өстәмә гариза бирү кирәклегеннән башка тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

36. КФҮдә кабул итүгә гариза бирүчеләрне язу (алга таба – язылу) Бердәм портал, Республика порталы, КФҮ контакт-үзәге телефоны ярдәмендә башкарыла.

Мөрәҗәгать итүчегә күпфункцияле үзәктә билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә кабул итү өчен теләсә кайсы буш датага һәм вакытка язылу мөмкинлеге бирелә.

Билгеле бер датага язылу бу дата башланырга бер тәүлек кала тәмамлана.

Алдан язылып куюны Бердәм портал, Республика порталы аша башкару өчен мөрәҗәгать итүчегә система соратып алган белешмәләрне күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта);

телефон номеры;

электрон почта адресы (теләк буенча);

кабул итүнең теләгән көне һәм вакыты.

Мөрәҗәгать итүче алдан язылганда хәбәр иткән белешмәләр мөрәҗәгать итүченең шәхсән кабул иткәндә тапшырган документларына туры килмәгән очракта, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Алдан язып куйганда мөрәҗәгать итүчегә талон-раслауны бастырып чыгару мөмкинлеге тәэмин ителә. Мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын хәбәр иткән очракта, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат та, кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, күрсәтелгән адреска җибәрелә.

Алдан язылуны башкарганда мөрәҗәгать итүчегә алдан язылуның билгеләнгән кабул итү вакытыннан 15 минут узгач, ул килмәгән очракта гамәлдән чыгарылуы турында мәҗбүри рәвештә хәбәр ителә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тартырга хокуклы.

Мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификация һәм аутентификация узудан тыш башка гамәлләр кылуны, кабул итүнең максатын күрсәтүне, шулай ук кабул итү өчен броньларга кирәк булган вакыт интервалы озынлыгын исәпләү өчен кирәкле белешмәләрне бирүне таләп итү тыела.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

38. Регламентка 3 нче кушымта таблицасында муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге китерелгән, алар бүленгән:

а) мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтү өчен үзе тапшырырга тиешле документлар;

б) мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтү өчен мөстәкыйль рәвештә тапшырырга хокуклы документлар.

39. Гариза формалары һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар турында белешмәләр шушы регламентның 3 нче кушымтасында китерелгән.

## III. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм башкару сроклары

Административ процедуралар исемлеге

40. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза һәм документлар кабул итү;

2) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

4) мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен күрсәтү.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек

41. Муниципаль хезмәтне алу өчен “Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы” федераль дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә түбәндәге ведомствоара мәгълүмат соратуларын җибәрергә кирәк:

1) “Җир кишәрлегенә һәм (яисә) капиталь төзелеш объектына күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә” мәгълүмати соратып алу. Күрсәтелгән мәгълүмати соратып алу муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып 1 эш көне эчендә “Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенә” җибәрелә. “Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль

хезмәте” соратып алына торган белешмәләрне ведомствоара гарызнамә җибәрелгән вакыттан алып 2 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыра;

2) “Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә” мәгълүмати соратып алу. Күрсәтелгән мәгълүмати соратып алу “Федераль салым хезмәтенә” муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып 1 эш көне дәвамында җибәрелә. “Федераль салым хезмәте” сорала торган белешмәләрне ведомствоара гарызнамә җибәрелгәннән соң 5 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыра. Гарызнамә юридик зат хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта гамәлгә ашырыла;

3) “Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә” мәгълүмати соратып алу. Күрсәтелгән мәгълүмати соратып алу “Федераль салым хезмәтенә” муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып 1 эш көне дәвамында җибәрелә. “Федераль салым хезмәте” сорала торган белешмәләрне ведомствоара гарызнамә җибәрелгәннән соң 5 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыра. Сорау хезмәт күрсәтүне сорап шәхси эшмәкәр мөрәҗәгать иткән очракта башкарыла.

42. Муниципаль хезмәтне алу өчен башка сервислар ярдәмендә түбәндәге ведомствоара мәгълүмати соратып алулар җибәрергә кирәк:

1) “Мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиле вәкаләтләрен раслый торган документ” мәгълүмати соратып алу. Күрсәтелгән мәгълүмат гарызнамәсе, хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итүче вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта, “Гражданлык хәле актларын язуларның Бердәм дәүләт реестры” сервисы йә “Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы” сервисы ярдәмендә 1 эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла;

2) “Ышанычнамә бирү факты һәм аның эчтәлеге турында белешмәләр” мәгълүмати соратып алу. Күрсәтелгән мәгълүмати соратып алу “Нотариатның Бердәм мәгълүмат системасы” сервисы ярдәмендә 2 эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла;

3) “Мәдәни мирас объектларын саклау зоналары чикләрендә игълан ителгән параметрлары булган капиталь төзелеш объектын урнаштыру яисә реконструкцияләү мөмкинлеге турында бәяләмә” мәгълүмати соратып алу. Күрсәтелгән мәгълүмати гарызнамә Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитетыннан (федераль, төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары өлешендә) йә Башкарма комитетның структур бүлекчәсеннән (җирле әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары өлешендә) 5 эш көненнән дә соңга калмыйча соратып алына;

4) “Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы” мәгълүмати соратып алу. Күрсәтелгән мәгълүмати соратып алу Башкарма комитетның структур бүлекчәсеннән 5 эш көненнән дә соңга калмыйча соратып алына;

5) “Территорияне планлаштыру документациясе” мәгълүмати соратып алу. Күрсәтелгән мәгълүмати соратып алу Башкарма комитетның структур бүлекчәсеннән 5 эш көненнән дә соңга калмыйча соратып алына;

6) “Капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерү турында элек кабул ителгән карар (элек килештерелгән архитектура-шәһәр төзелеше йөзе параметрлары үзгәргән очракта)” мәгълүмати соратып алу.

Күрсәтелгән мәгълүмати соратып алу Башкарма комитетның структур бүлекчәсеннән 5 эш көненнән дә соңга калмыйча соратып алына;

## IV.Муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гарызнамәне карау статусын үзгәртү турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү ысуллары

43. Техник мөмкинлеге булганда, мөрәҗәгать итүчегә әлеге Регламентта билгеләнгән хезмәт күрсәтү буенча аның гарызнамәсе статусы үзгәрүе (хезмәт күрсәтү өчен документлар кабул итү турында; гаризаны һәм документлар комплектын карау турында; хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен күрсәтү турында), шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтүнең күрсәтелгән этабында мөрәҗәгать итүче башкарырга тиешле адымнар һәм гамәлләр, санап үтелгән ысулларның берсе турында хәбәр ителә:

- смс-мәгълүмат бирү юлы белән;
- Бердәм портал ярдәмендә;
- Республика порталы аша;
- башка сервислар һәм ысуллар ярдәмендә (булган очракта).

1нче Кушымта

## ШАРТЛЫ БИЛГЕЛӘР ҺӘМ КЫСКАРТУЛАР ИСЕМЛЕГЕ

1. Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (https://uslugi.tatarstan.ru/) – Республика порталы;
2. Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы (https:// www.gosuslugi.ru/ – Бердәм портал;
3. “Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең федераль реестры” федераль дәүләт мәгълүмат системасы (http://frgu3.gosuslugi.ru) Реестр);
4. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты – Башкарма комитет;
5. “Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге” дәүләт бюджет учреждениесе – КФҮ.

2нче кушымта

**Мөрәҗәгать итүчеләр категориясенең (билгесенең) идентификаторы**

| № | Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе | Мөрәҗәгать итүченең аерым билгесе исеме | Мөрәҗәгать итүченең аерым билгесе идентификаторы |
|---|---|---|---|
| 1 | Капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше йөзен Килештерү | Физик зат | 1А |
| 2 | | Юридик зат | 2А |
| 3 | | Шәхси эшмәкәр | 3А |
| 4 | | Мөрәҗәгать итүченең вәкиле | 4А |

3нче кушымта

**Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге**

| № | Идентификатор | Мөрәҗәгать итүче тапшыра торган документлар төрләрен, төркемнән документлар санын расшифровкалау | Бирү ысулы |
|---|---|---|---|
| *Мөрәҗәгать итүче Хезмәт күрсәтү өчен үзе тапшырырга тиешле документлар* | | | |
| 1. | 1А-4А | Гариза | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 2. | 1А-4А | Шәхесне таныклаучы документ | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 3. | 4А | Мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ | Башкарма комитет, КФҮ |
| 4. | 1А-4А | Капиталь төзелеш объектының проект документациясе бүлекләре*:<br>а) аңлатма язуы;<br>б) җир кишәрлеген планлаштыру оештыру схемасы;<br>в) күләм-планлаштыру һәм архитектура чишелешләре. | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| *Мөрәҗәгать итүче Хезмәт күрсәтү өчен үзе тапшырырга хокуклы документлар* | | | |
| 1. | 1А-4А | Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрында хокуклары теркәлмәгән капиталь төзелеш объектына, җир кишәрлегенә хокук билгеләүче документлар | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |

** Проект документациясе бүлекләренең текст һәм график өлешенең эчтәлеге Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Проект документациясе бүлекләренең составы һәм аларның эчтәлегенә таләпләр турында» 2008 елның 16 февралендәге 87 номерлы карарына туры килергә тиеш.*

*Проект документациясенең дәүләт серенә кагылышлы белешмәләр булган бүлекләре Россия Федерациясенең дәүләт сере турындагы законнары таләпләрен үтәп тапшырыла.*

4нче кушымта

**Баш тарту өчен тулы нигезләр**
**муниципаль хезмәт күрсәтү һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны кабул итүдән баш тарту**

| № | Идентификатор | Мөрәҗәгать итүче тапшыра торган документлар төрләрен, төркемнән документлар санын расшифровкалау |
|---|---|---|
| *Хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр* | | |
| 1. | 1А-4А | Капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше йөзен билгели торган һәм проект документациясендәге йә төзүченең яисә капиталь төзелеш объектын проектлауга техник заказчының заданиесендәге архитектура карарларының капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше йөзенә шәһәр төзелеше регламентында күрсәтелгән, билгеләнгән таләпләргә туры килмәве<br>___<br>*(шәһәр төзелеше регламентын раслый торган норматив хокукый актның реквизитларын күрсәтергә)* |
| 16. | 1А-4А | шәһәр төзелеше регламентын раслый торган норматив хокукый актның реквизитларын күрсәтергә |
| *Гаризаны һәм хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр* | | |
| 1. | 1А-4А | Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларда текстны Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган чистартулар һәм төзәтүләр бар |
| 2. | 1А-4А | Документларда муниципаль хезмәт күрсәтү өчен документлардагы мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмдә файдаланырга мөмкинлек бирми торган зарарланулар бар |
| 3. | 1А-4А | Тапшырылган документлар яисә белешмәләр муниципаль хезмәтне сорап мөрәҗәгать итү вакытына үз көчен югалткан (шәхесне таныклаучы документ белешмәләре; мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен таныклаучы документ күрсәтелгән зат тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать ителгән очракта) |
| 4. | 1А-4А | Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны билгеләнгән таләпләрне бозып электрон |

| | | |
|---|---|---|
| | | рәвештә бирү |
| 5. | 1А-4А | Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы булмаган комплектын тапшыру |
| 6. | 1А-4А | Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза вәкаләтләренә муниципаль хезмәт күрсәтү кермәгән дәүләт хакимияте органына, җирле үзидарә органына яисә оешмага тапшырылган |
| 7. | 1А-4А | “Электрон имза турында” 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясында билгеләнгән көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаның чынбарлыгын тану шартларын үтәмәү |
| 8. | 1А-4А | Мөрәҗәгать итүче категориясенең хезмәт күрсәтү алуга хокукы булган затлар даирәсенә туры килмәве |

5нче кушымта

(Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган бланкы)

Капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше
йөзен килештерү турында
КАРАР
______________ № _________________

___ ____________ _____ номерлы капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерү турында карар бирүгә муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны карау нәтиҗәләре буенча _______________ _______________ архитектура-шәһәр төзелеше йөзен _________________________ адресы буенча төзелеш үткәргәндә килештерү турында карар кабул итте.

Капиталь төзелеш объектының(-лар) кадастр номеры(-лар):____________ кадастр номерлы җир кишәрлегендә урнашкан һәм түбәндәге төп параметрлары булган ___________________:

- _________________________;
- _________________________;
- _________________________;

Кушымта: капиталь төзелеш объектының (объектлар төркеменең) архитектур-шәһәр төзелеше йөзен тасвирлау материаллары.

| Электрон имза турында белешмәләр |
|---|

Район башкарма комитет җитәкчесе ____________________

6нчы кушымта

(Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган бланкы)

Капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерү турында карар бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту хакындагы
КАРАР

Мөрәҗәгать белән бәйле рәвештә ________________________________________
(Физик затның Ф.И.О., мөрәҗәгать итүче юридик затның исеме)

гариза № _______ _____._____.________ел,______________________________________турында

________________________________________________________________________________

нигез: ________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

тапшырылган документларны карау нәтиҗәләре буенча муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителде, түбәндәге белән бәйле рәвештә:

1.

2.

| Электрон имза турында белешмәләр |
|---|

Вазыйфаи зат (ФИО) ______________________________________

(имзалауны гамәлгә ашыручы органның вазыйфаи заты имзасы)

Башкаручы (ФИО)

_________________________

(башкаручының контактлары)

7нче кушымта

Юридик затлар өчен

(жирле үзидарә органы исеме)

___________________________________________

___________________________________________

(оешманың һәм оештыру-хокукый рәвешенең тулы исеме)

___________________________________________

йөзендә

___________________________________________

(Җитәкченең яисә башка вәкаләтле затның ФИО)

Мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклаучы документ:

___________________________________________

(документ төре)

___________________________________________

(серия, номер)

___________________________________________

(кем тарафыннан, кайчан бирелгән)

Юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр:

ОГРН

___________________________________________

___________________________________________

ИНН

___________________________________________

Тору урыны

___________________________________________

___________________________________________

Контакт мәгълүмат:

тел.номеры 1 ______________________________

тел.номеры 2 ______________________________

эл. почта ______________________________

Физик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр өчен

ФИО

___________________________________________

Шәхесне таныклаучы документ:

___________________________________________

(документ төре)

___________________________________________

(серия, номер)

___________________________________________

(кем тарафыннан, кайчан бирелгән)

ОРГНИП (ИП өчен)

___________________________________________

Регистрация адресы

Ышанычнамә буенча вәкил яки законлы вәкил:
ФИО

Шәхесне таныклаучы документ:

(документ төре)

(серия, номер)

(кем тарафыннан, кайчан бирелгән)

Вәкаләтләрне раслый торган документның реквизитлары:

Регистрация адресы

Контакт мәгълүмат:
тел.номеры 1 ____________________
тел.номеры 2 ____________________
эл. почта ____________________

ГАРИЗА ФОРМАСЫ

Объектның (объектлар төркеменең) архитектур-шәһәр төзелеше күренешен тәкъдим ителгән проект документациясе нигезендә килештерүгезне сорыйм.

Кирәкле белешмәләр исемлеге:

| | |
|---|---|
| Эш төре | |
| Җир кишәрлегенең кадастр номеры | |
| Капиталь төзелеш объектының кадастр номеры | |
| Объект(-лар) исеме | |
| Архитектура проекты авторының ФИО | |
| Территорияне планлаштыру документациясен раслау турында карар датасы | |
| Территорияне планлаштыру документациясен раслау турындагы карар номеры | |
| Территорияне планлаштыру документациясен раслаган орган исеме | |
| Архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерү турында элегрәк бирелгән карарның датасы | |
| Архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерү турында элек бирелгән карарның номеры | |

| | |
|---|---|
| Архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерү турында элегрәк карар биргән орган исеме | |
| Шундый ук күпфатирлы торак йортның архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерү турында карар датасы | |
| Шундый ук күпфатирлы торак йортның архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерү турында карар номеры | |
| Шундый ук күпфатирлы торак йортның архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерү турында карар биргән орган исеме | |
| Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен минем адреска түбәндәге ысул белән бирүегезне (җибәрүегезне) сорыйм: | |
| ☐ Электрон рәвештә дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталының шәхси кабинетына,<br>☐ Электрон рәвештә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының шәхси кабинетына<br>☐ Башкарма комитетка<br>☐ КФҮкә | |

Мөрәҗәгать итүченең имзасы ______________________

(имза расшифровкасы)

Дата ______________________________

8нче кушымта

(Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган бланкы)

Капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерү турында карар бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту хакында
КАРАР

Мөрәҗәгать итү сәбәпле_______________________________________________
(Ф.И.О. физического лица, наименование юридического лица – заявителя)

_____ номерлы гариза ______.______._________ел, ______________________________________

________________________________________________________________________________

нигез: ___________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

тапшырылган документларны карау нәтиҗәләре буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителде, түбәндәгеләр белән бәйле рәвештә:

1.

2.

Вазыйфаи зат (ФИО) ________________________________

(имзалауны гамәлгә ашыручы органның вазыйфаи заты имзасы)

| Электрон имза турында белешмәләр |
| --- |

Башкаручы (ФИО)

______________________________

(башкаручының контактлары)